ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**КАРАР**

29 ноябрь 2018ел

№ 7120

Башкарма комитетның «Муниципаль милектәге җир участогын сатулар үткәрмичә сату буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 31 июлендәге 4351 нче карарына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ санлы Федераль закон, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 нче карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезнамәнең 5.24 пункты, Башкарма комитетның 2011 елның 30 мартындагы 1576 нчы карары белән расланган Башкарма комитет тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләрнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе турында нигезнамә нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2015 елның 31 июлендәге 4351 нче карары белән (Башкарма комитетның 2016 елның 22 июнендәге 3187 нче карары редакциясендә) расланган муниципаль милектәге җир участогын сатулар үткәрмичә сату буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) преамбулада «Башкарма комитетның «Муниципаль һәм дәүләт хезмәтләре исемлеген раслау турында» 2013 елның 9 апрелендәге 2393 нче карары» сүзләрен «Башкарма комитетның «Муниципаль һәм дәүләт хезмәтләре исемлеген раслау турында» 2016 елның 13 маендагы 2363 нче карары» сүзләренә алмаштырырга;

2) 1.4 пунктта:

- 5 пунктчаны яңа редакциядә бәян итәргә:

«5) «Күчемсез милекне дәүләт теркәвенә алу турында» 2015 елның 13 июлендәге 218-ФЗ санлы Федераль закон (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 20.07.2015, №29 (I бүлек), ст. 4344) (алга таба – 218-ФЗ санлы Федераль закон);»;

- 9 пунктчаны яңа редакциядә бәян итәргә:

«9) «Яр Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге Вәкиллекле органының 2005 елның 8 декабрендәге 6/5 нче карары белән кабул ителгән «Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставы (Челнинские известия, №235-237, 10.12.2005, №249-250, 30.12.2005,) (алга таба – шәһәр Уставы);»;

- 10 пунктчаны яңа редакциядә бәян итәргә:

«10) Башкарма комитетның 2016 елның 13 маендагы 2363 нче карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләр исемлеге (алга таба – Муниципаль хезмәтләр исемлеге);»;

- 11 пунктчаны яңа редакциядә бәян итәргә:

«11) Башкарма комитетның 2017 елның 28 декабрендәге 1210-р санлы боерыгы белән расланган Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе турында нигезнамә (алга таба – Идарә турында нигезнамә);»;

2) 2.1 пункттагы «2393 нче карар» сүзләрен «Муниципаль хезмәтләр исемлеге» сүзләренә алмаштырырга;

3) 2.9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| 2.9. Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату яки кире кагу өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Хезмәт күрсәтүне туктату өчен нигезләр каралмаган.<br>Кире кагу өчен нигезләр:<br>1) җир участогы бирү турындагы гариза белән җир законнары нигезендә, җир участогын сатулар үткәрмичә сатып алуга хокукы булмаган зат мөрәҗәгать итү;<br>2) җир участогы бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир участогы даими (сроксыз) файдалануга, түләүсез файдалануга, гомерлек мирас итеп биләү яки аренда хокукында бирелү (җир участогы бирү турындагы гариза белән әлеге хокукларга ия булган зат мөрәҗәгать иткән яисә гариза РФ Җир кодексының 39.10 маддәсе 2 пунктының 10 пунктчасы нигезендә бирелгән очраклардан тыш);<br>3) җир участогы бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир участогы яшелчәчелек, бакчачылык, дача хуҗалыклары алып бару яки шәхси торак төзелеше максатларында территорияне комплекслы үзләштерү өчен гражданнар тарафыннан төзелгән коммерцияле булмаган оешмаларга бирелү (әгәр җир участогы гомуми файдаланудагы мөлкәткә караса, гариза белән әлеге коммерцияле булмаган оешма әгъзасы яисә коммерцияле булмаган оешма мөрәҗәгать иткән очраклардан тыш);<br>4) җир участогы бирү турындагы гаризада | РФ Җир кодексының 39.16 маддәсе |

| | | |
|---|---|---|
| | күрсәтелгән җир участогында гражданнарга яки юридик затларга караган бина, корылма, тәмамланмаган төзелеш объекты урнашу (җир участогында корылма (шул исәптән төзелеше тәмамланмаган корылма) сервитут нигезендә урнаштырылган яки җир участогында РФ Җир кодексының 39.36 маддәсенең 3 пунктында каралган объект урнаштырылган һәм рөхсәт ителгән файдалану нигезендә җир участогыннан файдалануга комачауламаган яисә җир участогы бирү турындагы гариза белән әлеге биналарның, корылмаларның, алар эчендәге бүлмәләрнең, әлеге төзелеше тәмамланмаган объектның милекчесе мөрәҗәгать иткән очраклардан тыш);<br>5) җир участогы бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир участогында дәүләт яки муниципаль милектәге бина, корылма, тәмамланмаган төзелеш объекты урнашу (җир участогында корылма (шул исәптән төзелеше тәмамланмаган корылма) сервитут нигезендә урнаштырылган яисә җир участогы бирү турындагы гариза белән әлеге биналар, корылмалар, алар эчендәге бүлмәләр, әлеге төзелеше тәмамланмаган объектның милекчесе мөрәҗәгать иткән очраклардан тыш);<br>6) җир участогы бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир участогының әйләнештән алынуы яки әйләнештә чикләнүе һәм җир участогы бирү турындагы гаризада күрсәтелгән хокукта аны бирү рөхсәт ителмәү;<br>7) җир участогы бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир участогы дәүләт яки муниципаль ихтыяҗлар өчен резервлану, гариза бирүче җир участогын резервлау турындагы карарның гамәлдә булу срогыннан арткан срокка җир участогын милеккә бирү турындагы гариза белән мөрәҗәгать иткән очракта (җир участогын резервлау максатларында бирү очрагыннан тыш);<br>8) җир участогы бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир участогы төзелгән территорияне үстерү турында башка зат белән килешү төзелгән территория чикләрендә урнашу (җир участогы бирү турындагы гариза белән әлеге җир участогында урнашкан | |

| | | |
|---|---|---|
| | биналарның, корылмаларның, алар эчендәге бүлмәләрнең, төзелеше тәмамланмаган объектның милекчесе яки андый җир участогының хокукка ия заты мөрәҗәгать иткән очраклардан тыш);<br>9) җир участогы бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир участогы төзелгән территорияне үстерү турында башка зат белән килешү төзелгән территория чикләрендә урнашу яки җир участогы төзелгән территорияне комплекслы үзләштерү турында башка зат белән килешү төзелгән җир участогыннан барлыкка килү (андый җир участогы федераль әһәмияткә ия объектларны, региональ әһәмияткә ия объектларны яки җирле әһәмияткә ия объектларны урнаштыру өчен билгеләнгән һәм андый җир участогын бирү турындагы гариза белән күрсәтелгән объектларны төзүгә вәкаләтле зат мөрәҗәгать иткән очраклардан тыш);<br>10) җир участогы бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир участогы, төзелгән территорияне комплексны үзләштерү турында яки төзелгән территорияне үстерү турында башка зат белән килешү төзелгән җир участогыннан барлыкка килү һәм территорияне планлаштыру буенча расланган документлар нигезендә федераль әһәмияткә ия объектларны, региональ әһәмияткә объектларны яки җирле әһәмияткә ия объектларны урнаштыру өчен билгеләнү (җир участогын арендага бирү турындагы гариза белән күрсәтелгән объектлар төзелеше буенча әлеге затның йөкләмәсе күздә тотылган территорияне комплексны үзләштерү турында килешү яки төзелгән территорияне үстерү турында килешү төзегән зат мөрәҗәгать иткән очраклардан тыш);<br>11) җир участогы бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир участогы, аукцион үткәрү турындагы хәбәр РФ Җир кодексының 39.11 маддәсенең 19 пункты нигезендә урнаштырылган аукционның предметы булып тору;<br>12) җир участогы бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир участогына карата аны сату буенча аукцион яки аны арендалау килешүе төзү хокукына аукцион үткәрү турында | |

| | | |
|---|---|---|
| | РФ Җир кодексының 39.11 маддәсенең 4 пункты 6 пунктчасында каралган гариза керү, андый җир участогы РФ Җир кодексының 39.11 маддәсендәге 4 пунктның 4 пунктчасы нигезендә барлыкка килү һәм вәкаләтле орган тарафыннан РФ Җир кодексының 39.11 маддәсенең 8 пунктында каралган нигезләр буенча әлеге аукцион үткәрүне кире кагу турында карар кабул ителмәү шарты белән;<br>13) җир участогы бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир участогына карата шәхси торак төзелеше, шәхси ярдәмче хуҗалык, бакчачылык, дача хуҗалыгы алып бару яки крестьян (фермер) хуҗалыгы эшчәнлеген гамәлгә ашыру турындагы хәбәр РФ Җир кодексының 39.18 маддәсендәге 1 пунктның 1 пунктчасы нигезендә басылып чыгу һәм урнаштырылу;<br>14) җир участогыннан рөхсәт ителгән файдалану андый җир участогыннан файдалануның җир участогы бирү турындагы гаризада күрсәтелгән максатларына туры килмәү (территорияне планлаштыруның расланган проекты нигезендә анда линия объекты урнаштыру очракларыннан тыш);<br>14.1) соратылган җир участогы тулысынча, җир участогы бирү турындагы гаризада күрсәтелгән шундый җир участогыннан файдалануның максатлары нигезендә, җир участокларыннан файдалануның билгеләнгән чикләүләре җир участогыннан файдалануга юл куймый торган территориядән файдалануның аерым шартлары булган зона чикләрендә урнашу;<br>15) соратылган җир участогы Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә расланган, оборона һәм куркынычсызлык ихтыяҗлары өчен бирелгән һәм вакытлыча әлеге ихтыяҗлар өчен файдаланылмый торган җир участоклары исемлегенә кертелмәү, җир участогы бирү турындагы гариза РФ Җир кодексының 39.10 маддәсендәге 2 пунктның 10 пунктчасы нигезендә бирелгән очракта;<br>16) яшелчәчелек, бакчачылык алып бару өчен гражданнар тарафыннан төзелгән коммерцияле булмаган оешмага җир участогы | |

| | | |
|---|---|---|
| | бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир участогының мәйданы федераль законнар нигезендә билгеләнгән чик күләменнән артып китү;<br>17) җир участогы бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир участогы территориаль планлаштыруның расланган документлары һәм (яки) территорияне планлаштыру документлары нигезендә федераль әһәмияткә ия объектларны, региональ әһәмияткә ия объектларны яки җирле әһәмияткә ия объектларны урнаштыру өчен билгеләнү һәм җир участогы бирү турындагы гариза белән әлеге объектларны төзүгә вәкаләтләнмәгән зат мөрәҗәгать итү;<br>18) җир участогы бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир участогы Россия Федерациясе дәүләт программасы, Россия Федерациясе субъектының дәүләт программасы нигезендә бина, корылма урнаштыру өчен билгеләнү һәм җир участогы бирү турындагы гариза белән әлеге бинаны, корылманы төзүгә вәкаләтләнмәгән зат мөрәҗәгать итү;<br>19) җир участогын хокукларның әлеге төрендә бирү рөхсәт ителмәү;<br>20) җир участогы бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир участогына карата рөхсәт ителгән файдалану төре билгеләнмәү;<br>21) җир участогы бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир участогы аерым категория җиргә кертелмәү;<br>22) җир участогы бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир участогына карата аны бирүне алдан килешенү турында карар кабул ителү һәм аның гамәлдәге срогы чыкмау һәм җир участогын бирү турында гариза белән әлеге карарда күрсәтелмәгән зат мөрәҗәгать итү;<br>23) җир участогы бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир участогы дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗлар өчен кире кайтарып алынган булу һәм андый җир участогын бирүнең гаризада күрсәтелгән максаты ул җир участогын кире кайтарып алу максатларына туры килмәү (андый җир участогында урнашкан күп фатирлы йортлар авария хәлендә һәм сүтелергә яки яңартып төзелергә | |

| | | |
|---|---|---|
| | тиеш дип танылган булу сәбәпле, дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗлар өчен кире кайтарып алынган җир участокларыннан тыш);<br>24) җир участогы бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир участогының чикләре «Күчемсез милекне дәүләт теркәвенә алу турында» Федераль закон нигезендә анықланырга тиеш булу;<br>25) җир участогы бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир участогының мәйданы җир участогының урнашу схемасында, территорияне межалау проектында яки урман участокларының проект документларында күрсәтелгән мәйданнан артып китү, шуның нигезендә ун процентган артык шундый җир участогы барлыкка килү;<br>26) Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ санлы Федераль законның 18 маддәсенең 4 бүлегендә каралган дәүләт мөлкәте исемлегенә яки муниципаль мөлкәт исемлегенә кертелгән җир участогын бирү турындагы гариза белән кече һәм урта эшмәкәрлек субъекты булып саналмаган зат яки аңа карата күрсәтелгән Федераль законның 14 маддәсенең 3 бүлеге нигезендә ярдәм күрсәтү мөмкин булмаган зат мөрәҗәгать итү. | |

2.13 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| 2.13. Гариза бирүченең муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы запросын теркәү срогы, шул исәптән электрон рәвештә | Гариза кергән вакыттан башлап бер көн эчендә.<br>Ял (бәйрәм) көнендә электрон рәвештә кергән запрос ял (бәйрәм) көненнән соң килүче эш көнендә теркәлә. | Эш регламенты |

4) 3.3.2 пунктта «Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасарына» сүзләрен «ҖММИ башлыгына» сүзләренә алмаштырырга;

5) 3.3.3 пунктны төшереп калдырырга:

6) 3.4.2 пунктның икенче абзацын яңа редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар түбәндәге срокларда гамәлгә ашырыла:

- Росреестр белгечләренә җибәрелә торган документлар (мәгълүматлар) буенча, өч эш көненнән артмаган срокта;

- башка тәэмин итүчеләр буенча – федераль законнарда, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең хокукый актларында һәм федераль законнар нигезендә кабул ителгән Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында ведомствоара запроска җавап әзерләү һәм җибәрүнең башка сроклары билгеләнмәгән очракта, документ яки мәгълүмат бирә торган органга яки оешмага ведомствоара запрос кергән көннән башлап биш көн эчендә.»;

7) 3.5.10 пункттагы «Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасарына» сүзләрен «Башкарма комитет Җитәкчесенә» сүзләренә алмаштырырга;

8) 3.5.11 пункттагы тиешле санда һәм килештәге «Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары» сүзләрен тиешле сандагы һәм килештәге «Башкарма комитет Җитәкчесе» сүзләренә алмаштырырга;

9) 4.2. пункттагы «муниципаль хезмәт күрсәтү буенча эшне оештыру өчен җаваплы Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары» сүзләрен «Башкарма комитет Җитәкчесе» сүзләренә алмаштырырга;

10) 4.4 пункттагы «Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары» сүзләрен «Башкарма комитетның ҖММИ башлыгы» сүзләренә алмаштырырга;

11) түбәндәге эчтәлектәге 4.5 пункт белән тулыландырырга:

«4.5. Муниципаль хезмәт күрсәтүне гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары ягыннан контрольдә тоту муниципаль хезмәт күрсәткәндә Башкарма комитет эшчәнлегенең ачыклыгы, муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм дөрес мәгълүмат алу һәм муниципаль хезмәт күрсәтү процессында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр карап тикшерү мөмкинлеге аша гамәлгә ашырыла.»;

12) 5 бүлекнең исемен яңа редакциядә бәян итәргә:

«5. Башкарма комитетның, аның вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең, шулай ук КФҮнең, КФҮ хезмәткәрләренең карарларына һәм эш итүләренә (эш итмәүләренә) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү тәртибе»;

13) 5.1 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль хезмәттән файдаланучылар Башкарма комитетның муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы хезмәткәрләренең карарларына, эш итүләренә (эш итмәүләренә) судка кадәр тәртиптә – Башкарма комитетка, КФҮ хезмәткәрләре буенча – КФҮгә яисә КФҮне оештыручы булып исәпләнгән гавами-хокукый берәмлекнең тиешле дәүләт хакимияте органына (җирле үзидарә органына) шикаять бирергә хокуклы.

Гариза бирүче шикаять белән мөрәҗәгать итәргә мөмкин, шул исәптән түбәндәге очракларда:

1) гариза бирүченең муниципаль хезмәт күрсәтү турында запросын, 210-ФЗ санлы Федераль законның 15.1. маддәсендә күрсәтелгән запросны теркәү срогын бозу;

2) муниципаль хезмәт күрсәтү срогын бозу;

3) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен гариза бирүчедән Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең хокукый актларында каралмаган документларны таләп итү;

4) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен гариза бирүчедән Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең хокукый актларында тапшыру каралган документларны кабул итүдән баш тарту;

5) баш тарту өчен нигезләр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасының законнарында һәм норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең хокукый актларында каралмаган очракта, муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту;

6) муниципаль хезмәт күрсәткәндә гариза бирүчедән Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең хокукый актларында каралмаган түләү таләп итү;

7) Башкарма комитетның, Башкарма комитет вазыйфаи затының, КФҮнең, КФҮ хезмәткәренең муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән ялгышларны һәм хаталарны төзәтүдән баш тарту яисә андый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозу;

8) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча документлар бирү срогын яки тәртибен бозу;

9) туктату нигезләре федераль законнарда һәм аларга туры китереп кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларында, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең хокукый актларында каралмаган очракта, муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату;

10) муниципаль хезмәт күрсәткәндә гариза бирүчедән 210-ФЗ санлы Федераль законның 7 маддәсендәге 1 бүлекнең 4 пунктында каралган очраклардан тыш, муниципаль хезмәт күрсәтүдән яисә муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән беренчел баш тартканда булмавы һәм (яки) дөрес булмавы күрсәтелмәгән документларны яки мәгълүматны таләп итү.».

14) 5.2 һәм 5.3 пунктларны яңа редакциядә бәян итәргә:

«5.2. Шикаять язма рәвештә кәгазьдә яки электрон төрдә бирелә.

Шикаять почта аша, КФҮ аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтыннан (http://www.nabchelny.ru), КФҮнең рәсми сайтыннан, Татарстан Республикасының бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан (http://uslugi.tatar.ru/), Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталыннан (http://www.gosuslugi.ru/) файдаланып җибәрелергә мөмкин, шулай ук гариза бирүчене шәхси кабул иткәндә кабул ителергә мөмкин.

5.3. Шикаятьне карап тикшерү срогы – ул теркәлгән көннән башлап унбиш эш көне эчендә. Башкарма комитетның, КФҮнең гариза бирүчедән документларны кабул итүдән яисә җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуыннан риза булмыйча шикаять бирелгән очракта яки шундый төзәтүләрнең билгеләнгән срогы бозылудан риза булмыйча шикаять бирелгән очракта – ул теркәлгән көннән башлап биш эш көне эчендә.»;

9) 5.4 пунктта:

- 1 пунктчаны «Башкарма комитетның муниципаль хезмәткәре» сүзләреннән соң «КФҮ, аның җитәкчесе һәм (яки) хезмәткәре» сүзләре белән тулыландырырга;

- 3 пунктчаны «КФҮ, КФҮ хезмәткәре;» сүзләре белән тулыландырырга;

- 4 пунктчаны «КФҮ, КФҮ хезмәткәре;» сүзләре белән тулыландырырга;

15) 5.7 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

5.7. Шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документлардагы хаталарны һәм ялгышларны төзәтү, Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда түләтү каралмаган акчаларны гариза бирүчегә кире кайтару рәвешендә;

2) шикаятьне канәгатьләндерү кире кагыла.»;

16) 5.8 пунктны түбәндәге эчтәлектәге икенче һәм өченче абзацлар белән тулыландырырга:

«Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта, гариза бирүчегә әлеге Регламентның 5.7 пунктында күрсәтелгән җавапта, муниципаль хезмәт күрсәткәндә ачыкланган кимчелекләрне тиз арада бетерү максатында Башкарма комитет, КФҮ тарафыннан гамәлгә ашырыла торган эшләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук тудырылган уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм муниципаль хезмәттән файдалану максатында гариза бирүче башкарырга тиешле алдагы гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш түгел дип танылган очракта, гариза бирүчегә әлеге Регламентның 5.7 пунктында күрсәтелгән җавапта кабул ителгән карар сәбәпләре турында дәлилләнгән аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат бирелә.»;

17) түбәндәге эчтәлектәге 5.9 һәм 5.10 пунктлар белән тулыландырырга:

«5.9. Шикаять тулысынча яки өлешчә канәгатьләндерелгән очракта, кимчелекләрне бетерү максатында кабул ителергә тиешле чаралар билгеләнә.

Шикаятьне карап тикшерү барышында яки аның нәтиҗәләре буенча административ хокук бозулар яки җинаять составы билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карап тикшерү вәкаләтләре бирелгән вазыйфаи зат, хезмәткәр булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрә.

5.10. Гариза бирүчеләр Башкарма комитетның, аның вазыйфаи затларының, шулай ук КФҮнең, КФҮ белгечләренең карарларына, эш итүләренә (эш итмәүләренә) Россия Федерациясе законнары нигезендә суд тәртибендә шикаять бирергә хокуклы.»;

18) 1 нче кушымтаны әлеге карарга 1 нче кушымтада каралганча яңа редакциядә бәян итәргә;

19) 3 нче кушымтаны әлеге карарга 2 нче кушымтада каралганча яңа редакциядә бәян итәргә;

20) 4 нче кушымтаны әлеге карарга 3 нче кушымтада каралганча яңа редакциядә бәян итәргә;

21) кушымтаны (белешмә) әлеге карарга 4 нче кушымтада каралганча яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы Л.Р. Гыйззәтуллинга әлеге карарны, имзаланган көннән башлап җиде көн срокта, «Челнинские известия» газетасында бастырып чыгаруны, «Интернет» челтәрендә ТР хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы Л.Р. Гыйззәтуллинга йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы — И.С. Зуев

Башкарма комитетның
2018 елның 29 ноябрендәге
7120 нче карарына
1 нче кушымта

Муниципаль милектәге җир участогын
сатулар үткәрмичә сату буенча
муниципаль хезмәт күрсәтүнең
административ регламентына
1 нче кушымта

Россия Федерациясе Җир кодексыннан өземтә

39.3 маддә. Дәүләт яки муниципаль милектәге җир участокларын сатуларда һәм сатулар үткәрмичә сату очраклары

2. Сатулар үткәрмичә түбәндәгеләрне сату гамәлгә ашырыла:

1) территорияне комплекслы үзләштерү өчен арендага бирелгән җир участогыннан барлыкка килгән җир участокларын (эконом класслы торак төзү максатларында территорияне комплекслы үзләштерү өчен, мондый торак төзү максатларында территорияне комплекслы үзләштерү турында килешү төзегән юридик затка бирелгән җир участогыннан барлыкка килгән җир участокларыннан тыш) Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә территорияне комплекслы үзләштерү турында килешү төзегән затка, әгәр әлеге пунктның 2 һәм 4 пунктчаларында башкача каралмаган булса;

1.1) территорияне комплекслы үзләштерү максатларында «Торак төзелеше үсешенә ярдәм күрсәтү турында» 2008 елның 24 июлендәге 161-ФЗ санлы Федераль закон нигезендә төзелгән аренда килешүе яки түләүсез файдалану килешүе буенча бирелгән җир участогыннан барлыкка килгән җир участокларын;

2) шәхси торак төзү максатларында территорияне комплекслы үзләштерү өчен гражданнар тарафыннан төзелгән коммерцияле булмаган оешмага бирелгән җир участогыннан барлыкка килгән җир участокларын (гомуми файдаланудагы мөлкәткә караган җир участокларыннан тыш), әлеге коммерцияле булмаган оешма әгъзаларына яки, әгәр әлеге коммерцияле булмаган оешма әгъзаларының гомуми җыелышы карарында күздә тотылган булса, әлеге коммерцияле булмаган оешмага;

3) бакчачылык, яшелчәчелек, дача хуҗалыгы алып бару өчен гражданнар тарафыннан төзелгән коммерцияле булмаган оешмага бирелгән җир участогыннан барлыкка килгән җир участокларын (гомуми файдаланудагы мөлкәткә караган җир участокларыннан тыш) әлеге коммерцияле булмаган оешма әгъзаларына;

4) шәхси торак төзү максатларында территорияне комплекслы үзләштерү өчен гражданнар тарафыннан төзелгән коммерцияле булмаган оешмага бирелгән һәм гомуми файдаланудагы мөлкәткә караган җир участогын бүлү нәтиҗәсендә барлыкка килгән җир участогын әлеге коммерцияле булмаган оешмага;

5) дача хуҗалыгы алып бару өчен юридик затка бирелгән һәм гомуми файдаланудагы мөлкәткә караган җир участогын бүлү нәтиҗәсендә барлыкка килгән җир участокларын күрсәтелгән юридик затка;

6) РФ Җир кодексының 39.20 маддәсендә каралган очракларда, биналар, корылмалар урнашкан җир участокларын шундый биналар, корылмалар яисә алар эчендәге бүлмәләр милекчеләренә;

7) юридик затларның даими (сроксыз) файдалануында булган җир участокларын күрсәтелгән юридик затларга (РФ Җир кодексының 39.9 маддәсенең 2 пунктында күрсәтелгән затлардан тыш);

8) җир участокларын крестьян (фермер) хуҗалыгына яки «Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр әйләнеше турында» Федераль законда билгеләнгән очракларда авыл хуҗалыгы оешмасына;

9) авыл хуҗалыгы производствосын алып бару өчен билгеләнгән һәм гражданга яки юридик затка арендага бирелгән җир участокларын, әгәр әлеге граждан яки әлеге юридик зат тарафыннан мондый җир участогын сатып алу-сату килешүе төзү турында гариза сатуларны үткәрмичә, җир участогын арендалау буенча күрсәтелгән килешүнең срогы чыккан көнгә кадәр бирелгән очракта, вәкаләтле органда дәүләт җир күзәтчелеге кысаларында ачыкланган мәгълүмат һәм мондый җир участогыннан файдаланганда Россия Федерациясе законнарын бозу очраклары булмау шарты белән, әлеге граждан яки әлеге юридик зат белән аренда килешүе төзелгән яисә әлеге гражданга яки әлеге юридик затка җир участогын арендалау килешүе буенча хокук һәм бурычларны тапшыру вакыттан башлап өч ел узгач бу гражданга яки бу юридик затка;

10) РФ Җир кодексының 39.18 маддәсе нигезендә җир участокларын шәхси торак төзү, торак пункт чикләрендә шәхси ярдәмче хуҗалык, бакчачылык, дача хуҗалыгы алып бару өчен гражданнарга, крестьян (фермер) хуҗалыгы тарафыннан аның эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен гражданнарга яки крестьян (фермер) хуҗалыкларына;

11) җир участокларын «Дәүләт яки муниципаль милектәге һәм Ерак Көнчыгыш федераль округы составына керүче Россия Федерациясе субъектлары территорияләрендә урнашкан җир участокларын гражданнарга бирү үзенчәлекләре турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль закон нигезендә гражданнарга.

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе

Г.К. Әхмәтова

Башкарма комитетның
2018 елның 29 ноябрендәге
7120 нче карарына
2 нче кушымта

Муниципаль милектәге җир участогын
сатулар үткәрмичә сату буенча
муниципаль хезмәт күрсәтүнең
административ регламентына
3 нче кушымта

Гариза бирүченең җир участогын сатулар үткәрмичә түләү нигезендә милеккә сатып алу хокукын раслаучы документлар исемлегеннән өземтә

| Т/с | Сатулар үткәрмичә җир участогы бирү нигезе | Җир участогын түләүсез яки түләү нигезендә бирү гамәлгә ашырыла торган хокук төре | Гариза бирүче | Җир участогы | Гариза бирүченең сатулар үткәрмичә җир участогы сатып алу хокукын раслаучы һәм җир участогына хокукларны сатып алу турында гаризага теркәлә торган документлар*(1) |
|---|---|---|---|---|---|
| 1. | Россия Федерациясе Җир кодексының (алга таба – Җир кодексы) 39.3 маддәсендәге 2 пунктның 1 пунктчасы *(2) | Түләү нигезендә милеккә | Территорияне комплекслы үзләштерү турында килешү төзегән юридик зат | Территорияне комплекслы үзләштерү өчен арендага бирелгән җир участогыннан барлыкка килгән җир участогы | Территорияне комплекслы үзләштерү турында килешү<br>* Күчемсез милек объекты (ҖУ) турында (соралган җир участогы турында) Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә<br>* Планлаштыруның расланган проекты һәм территорияне межалауның расланган проекты<br>* Гариза бирүче булып торган юридик зат турында Бердәм |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | дәүләт юридик затлар реестрыннан өземтә |
| 2. | Җир кодексының 39.3 маддәсендәге 2 пунктның 2 пунктчасы | Түләү нигезендә милеккә | Шәхси торак төзү максатларында территорияне комплекслы үзләштерү өчен җир участогы бирелгән гражданнар тарафыннан төзелгән коммерцияле булмаган оешма әгъзасы | Шәхси торак төзү максатларында территорияне комплекслы үзләштерү өчен гражданнар тарафыннан төзелгән коммерцияле булмаган оешмага бирелгән җир участогыннан барлыкка килгән җир участогы | Гариза бирүченең коммерцияле булмаган оешмада әгъза булып торуын раслаучы документ<br>Коммерцияле булмаган оешма органының соралган җир участогын гариза бирүчегә бүлеп бирү турында карары<br>Территорияне комплекслы үзләштерү турында килешү<br>* Күчемсез милек объекты (ҖУ) турында (соралган җир участогы турында) Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә<br>* Гариза бирүче булып торган юридик зат турында Бердәм дәүләт юридик затлар реестрыннан өземтә<br>* Планлаштыруның расланган проекты һәм территорияне межалауның расланган проекты |
| 2.1 | Җир кодексының 39.3 маддәсендәге 2 пунктның 2 пунктчасы | Түләү нигезендә милеккә | Шәхси торак төзү максатларында территорияне комплекслы үзләштерү өчен җир участогы бирелгән гражданнар тарафыннан | Шәхси торак төзү максатларында территорияне комплекслы үзләштерү өчен гражданнар тарафыннан төзелгән коммерцияле булмаган оешмага | Коммерцияле булмаган оешма органының җир участогын сатып алу турында карары<br>Территорияне комплекслы үзләштерү турында килешү<br>* Планлаштыруның расланган проекты һәм территорияне межалауның расланган проекты |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | төзелгән коммерцияле булмаган оешма | бирелгән җир участогын бүлү нәтиҗәсендә барлыкка килгән шәхси торак төзү өчен билгеләнгән җир участогы | * Күчемсез милек объекты турында (соралган җир участогы турында) Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә<br>* Гариза бирүче булып торган юридик зат турында Бердәм дәүләт юридик затлар реестрыннан өземтә |
| 3. | Җир кодексының 39.3 маддәсендәге 2 пунктның 3 пунктчасы | Түләү нигезендә милеккә | Бакчачылык, яшелчәчелек, дача хуҗалыгы алып бару өчен җир участогы бирелгән гражданнар тарафыннан төзелгән коммерцияле булмаган оешма әгъзасы | Бакчачылык, яшелчәчелек, дача хуҗалыгы алып бару өчен гражданнар тарафыннан төзелгән коммерцияле булмаган оешмага бирелгән җир участогыннан барлыкка килгән, бакчачылык яки яшелчәчелек өчен билгеләнгән җир участогы | Гариза бирүченең соралаган җир участогына хокукларын раслаучы (билгеләүче) документлар, әгәр шундый җир участогына хокук Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрында теркәлмәгән булса<br>Гариза бирүченең коммерцияле булмаган оешмада әгъза булып торуын раслаучы документ<br>Коммерцияле булмаган оешма органының җир участогын гариза бирүчегә бүлеп бирү турында карары<br>* Территорияне межалауның расланган проекты<br>* Коммерцияле булмаган берләшмәнең территорияне оештыру һәм төзү проекты (территорияне межалауның расланган проекты булмаган очракта) |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | * Күчемсез милек объекты турында (соралган җир участогы турында) Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә<br>* Гариза бирүче булып торган юридик зат турында Бердәм дәүләт юридик затлар реестрыннан өземтә |
| 4. | Җир кодексының 39.3 маддәсендәге 2 пунктның 4 пунктчасы | Түләү нигезендә милеккә | Шәхси торак төзү максатларында территорияне комплекслы үзләштерү өчен җир участогы бирелгән граждannar тарафыннан төзелгән коммерцияле булмаган оешма | Шәхси торак төзү максатларында территорияне комплекслы үзләштерү өчен гражданнар тарафыннан төзелгән коммерцияле булмаган оешмага бирелгән һәм гомуми файдаланудагы мөлкәткә караган җир участогын бүлү нәтиҗәсендә барлыкка килгән җир участогы | Коммерцияле булмаган оешма органының гомуми файдаланудагы мөлкәткә караган җир участогын сатып алу турында карары<br>* Территорияне комплекслы үзләштерү турында килешү<br>* Күчемсез милек объекты турында (соралган җир участогы турында) Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә<br>* Гариза бирүче булып торган юридик зат турында Бердәм дәүләт юридик затлар реестрыннан өземтә |
| 5. | Җир кодексының 39.3 маддәсендәге 2 пунктның 5 пунктчасы | Түләү нигезендә милеккә | Дача хуҗалыгы алып бару өчен җир участогы бирелгән юридик зат | Дача хуҗалыгы алып бару өчен юридик затка бирелгән һәм гомуми файдаланудагы мөлкәткә караган җир участогын бүлү нәтиҗәсендә | Юридик зат органының гомуми файдаланудагы мөлкәткә караган җир участогын сатып алу турында карары<br>Гариза бирүченең соралган җир участогына хокукларын раслаучы (билгеләүче) |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | барлыкка килгән җир участогы | документлар, әгәр шундый җир участогына хокук Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрында теркәлмәгән булса<br>*Территорияне межалауның расланган проекты<br>* Коммерцияле булмаган берләшмәнең территорияне оештыру һәм төзү проекты (территорияне межалауның расланган проекты булмаган очракта)<br>* Күчемсез милек объекты турында (соралган җир участогы турында) Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә<br>* Гариза бирүче булып торган юридик зат турында Бердәм дәүләт юридик затлар реестрыннан өземтә |
| 6. | Җир кодексының 39.3 маддәсендәге 2 пунктның 6 пунктчасы | Түләү нигезендә милеккә | Бина, корылма яисә бина, корылма эчендәге бүлмә милекче | Бина, корылма урнашкан җир участогы | Гариза бирүченең бинага, корылмага хокукларын раслаучы (билгеләүче) документ, әгәр шундый бинага, корылмага хокук Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрында теркәлмәгән булса<br>Гариза бирүченең соралган җир участогына хокукларын раслаучы (билгеләүче) документ, әгәр шундый җир участогына хокук Бердәм |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | дәүләт күчемсез милек реестрында теркәлмәгән булса (җир участогына тиешле хокуклар булганда)<br>Гариза бирүченең (гариза бирүчеләрнең), тиешле хокукта гариза бирүчегә караган биналарның, корылмаларның кадастр (шартлы, инвентарь) номерлары һәм адрес ориентирлары күрсәтелгән, соралган җир участогында урнашкан барлык биналарның, корылмаларның исемлеген үз эченә алган хәбәре<br>* Күчемсез милек объекты турында (соралган җир участогы турында) Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә<br>* Күчемсез милек объекты турында (соралган җир участогында урнашкан бина һәм (яки) корылма турында) Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә<br>* Күчемсез милек объекты турында (бүлмә милекчесе мөрәҗәгать иткән очракта, соралган җир участогында урнашкан бина, корылма эчендәге бүлмә турында) Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | * Гариза бирүче булып торган юридик зат турында Бердәм дәүләт юридик затлар реестрыннан өземтә<br>* Гариза бирүче булып торган шәхси эшмәкәр турында Бердәм дәүләт шәхси эшмәкәрләр реестрыннан өземтә |
| 7. | Җир кодексының 39.3 маддәсендәге 2 пунктның 7 пунктчасы | Түләү нигезендә милеккә | Җир участогынныын даими (сроксыз) файдалану хокукында файдаланучы юридик зат | Юридик затның даими (сроксыз) файдалану хокукында булган җир участогы | Гариза бирүченең соралаган җир участогына хокукларын раслаучы (билгеләүче) документлар, әгәр шундый җир участогына хокук Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрында теркәлмәгән булса<br>* Күчемсез милек объекты турында (соралган җир участогы турында) Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә<br>* Гариза бирүче булып торган юридик зат турында Бердәм дәүләт юридик затлар реестрыннан өземтә |
| 8. | Җир кодексының 39.3 маддәсендәге 2 пунктның 8 пунктчасы | Түләү нигезендә милеккә | Муниципаль милектәге җир өлешләре хисабына бүлеп бирелгән һәм муниципаль милектәге җир участогыннан файдаланучы | Муниципаль милектәге җир өлешләре хисабына бүлеп бирелгән һәм муниципаль милектәге җир участогы | * Күчемсез милек объекты турында (соралган җир участогы турында) Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә<br>* Гариза бирүче булып торган юридик зат турында Бердәм дәүләт юридик затлар |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | крестьян (фермер) хуҗалыгы яки авыл хуҗалыгы оешмасы | | реестрыннан өземтә<br>* Гариза бирүче булып торган шәхси эшмәкәр турында Бердәм дәүләт шәхси эшмәкәрләр реестрыннан өземтә |
| 9. | Җир кодексының 39.3 маддәсендәге 2 пунктның 9 пунктчасы | Түләү нигезендә милеккә | Авыл хуҗалыгы производствосын алып бару өчен билгеләнгән җир участогының арендаторы булып торучы граждан яки юридик зат | Авыл хуҗалыгы производствосын алып бару өчен билгеләнгән һәм аренда килешүе нигезендә өч елдан артык файдаланыла торган җир участогы | * Күчемсез милек объекты турында (соралган җир участогы турында) Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә<br>* Гариза бирүче булып торган юридик зат турында Бердәм дәүләт юридик затлар реестрыннан өземтә<br>* Гариза бирүче булып торган шәхси эшмәкәр турында Бердәм дәүләт шәхси эшмәкәрләр реестрыннан өземтә |

*(1) Документлар төп нөсхәдә (документлар һәркем өчен мөмкин булган очракта, күчермәдә) яисә җир участогына хокук алу турында гаризаны кабул итүче башкарма хакимият органының яки җирле үзидарә органының вазыйфаи заты тарафыннан раслана торган күчермәләрдә тапшырыла (җибәрелә).

*(2) Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 2001, № 44, ст. 4147; 2014, № 26, ст. 3377.

*(3) "*" символы белән билгеләнгән документлар, ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек ярдәмендә, дәүләт яки муниципаль милектәге җир участоклары белән эш итүгә вәкаләтле орган (алга таба – вәкаләтле орган) тарафыннан сорала. Соралган җир участогын булдырырга кирәк булган очракта, күчемсез милек объекты турында (соралган җир участогы турында) Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә җир участогына хокукларны сатып алу турында турындагы гаризага теркәлми һәм җир участогы аны бирүне алдан килешенеп бирелгәндә, вәкаләтле орган тарафыннан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек ярдәмендә соратып алынмый. Әгәр бинага, корылмага, төзелеше тәмамланмаган төзелеш объектына хокук әлеге хокукны Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрында дәүләт теркәвенә алу моментына бәйсез рәвештә, федераль закон көченә кергән дип саналган очракта, күчемсез милек объекты турында (соралган җир участогында урнашкан бина, корылма яки тәмамланмаган төзелеш объекты турында) Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә  җир участогына хокук сатып алу турындагы гаризага теркәлми һәм вәкаләтле орган тарафыннан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек ярдәмендә соратып алынмый.

*(4) Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 1997, № 30, ст. 3594; 2001, № 11, ст. 997; № 16, ст. 1533; 2002, № 15, ст. 1377; 2003, № 24, ст. 2244; 2004, № 27, ст. 2711; № 30, ст. 3081; № 35, ст. 3607; № 45, ст. 4377; 2005, № 1, ст. 15, 22, 40, 43; № 50, ст. 5244; 2006, № 1, ст. 17; № 17, ст. 1782; № 23, ст. 2380; № 27, ст. 2881; № 30, ст. 3287; № 50, ст. 5279; № 52, ст. 5498; 2007, № 31, ст. 4011; № 41, ст. 4845; № 43, ст. 5084; № 46, ст. 5553; № 48, ст. 5812; 2008, № 20, ст. 2251; № 27, ст. 3126; № 30, ст. 3597, 3616; № 52, ст. 6219; 2009, № 1, ст. 14; № 19, ст. 2283; № 29, ст. 3611; № 52, ст. 6410, 6419; 2010, № 15, ст. 1756; № 25, ст. 3070; № 49, ст. 6424; 2011, № 1, ст. 47; № 13, ст. 1688; № 23, ст. 3269; № 27, ст. 3880; № 30, ст. 4562, 4594; № 48, ст. 6730, № 49, ст. 7056, 7061; № 50, ст. 7359, 7347, 7365; № 51, ст. 7448; 2012, № 24, ст. 3078; № 27, ст. 3587; № 29, ст. 3998; № 31, ст. 4322; № 53, ст. 7619, 7643; 2013, № 14, ст. 1651; № 19, ст. 2328; № 30, ст. 4072, 4077, 4083, 4084; № 44, ст. 5633, № 51, ст. 6699, 2014, № 11, ст. 1098; № 26, ст. 3377; № 30, ст. 4218, 4225, № 43, ст. 5799; № 48, ст. 6637.

(5) Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 2001, № 44, ст. 4148; 2003, № 50, ст. 4846; 2004, № 41, ст. 3993; 2005, № 1, ст. 17; № 25, ст. 2425; 2006, № 1, ст. 3, 17; № 27, ст. 2881; № 52, ст. 5498; 2007, № 31, ст. 4009; № 43, ст. 5084; № 48, ст. 5812; 2008, № 30, ст. 3597; 2009, № 19, ст. 2281; № 52, ст. 6418, 6427; 2011, № 1, ст. 47; № 13, ст. 1688; № 30, ст. 4562; № 49, ст. 7027; № 51, ст. 7448; 2012, № 27, ст. 3587; № 53, ст. 7614, 7615; 2013, № 23, ст. 2881; № 27, ст. 3477; № 30, ст. 4072; 2014, № 26, ст. 3377; 2015, № 1, ст. 9; № 24, ст. 3369.

*(6) Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 2013, № 14, ст. 1652; № 27, ст. 3480; № 52, ст. 6961; 2014, № 23, ст. 2925, № 30, ст. 4225; № 48, ст. 6637; № 49, ст. 6925.

*(7) Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 2012, № 53, ст. 7600; 2013, № 52, ст. 6961.

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе


УПРАВЛЕНИЕ ДЕЛОПРОИЗВОДСТВОМ
ЭШ КӘГАЗЬЛӘРЕН АЛЫП БАРУ ИДАРӘСЕ


Г.К. Әхмәтова

Башкарма комитетның
2018 елның 29 ноябрендәге
7120 нче карарына
3 нче кушымта

Муниципаль милектәге җир участогын
сатулар үткәрмичә сату буенча
муниципаль хезмәт күрсәтүнең
административ регламентына
4 нче кушымта

Муниципаль хезмәт күрсәтү буенча эзлеклелекнең блок-схемасы




ҖММИ бүлеге белгече, норматив хокукый базаны исәпкә алып, гаризаны һәм документларны карап тикшерә һәм ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы ярдәмендә, Регламентның 2.6 пуктында күрсәтелгән документларны бирү турында электрон рәвештә запрослар җибәрә
Мәгълүмат белән тәэмин итүчеләрнең белгечләре запрослар нигезендә соралган документларны бирәләр
ҖММИ бүлеге белгече кергән документлар нигезендә карар проектын әзерләүне гамәлгә ашыра һәм килешенү өчен ҖММИ бүлеге башлыгына җибәрә
Җир участогын сатып алу-сату турында килешү проекты (алга таба – килешү проекты)
Муниципаль хезмәт күрсәтүне кире кагу турында хат (алга таба – кире кагу турында хат)
ҖММИ бүлеге башлыгы килешү проектын карап тикшерә, килешенә һәм аны килешенү өчен яисә кире кагу турындагы хатны имзалау өчен ҖММИ башлыгына җибәрә
ҖММИ башлыгына җибәрелгән килешү проекты яисә кире кагу турында хат
ҖММИ бүлеге башлыгы килешү проектын яисә кире кагу турындагы хатны карап тикшерә һәм:
- килешү проектын килешенә һәм килешенү өчен архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсенә җибәрә;
- кире кагу турындагы хатны имзалый һәм әлеге хатны эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә җибәрә
Килешенү өчен архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсенә җибәрелгән килешү проекты
Имзаланган һәм эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә җибәрелгән кире кагу турында хат
Эш кәгазьләрен алып бару идарәсе бүлеге белгече кире кагу турында хатны терки һәм аны гариза бирүчегә җибәрә
Имзаланган һәм гариза бирүчегә җибәрелгән кире кагу турында хат

Архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсе килешү проектын карап тикшерә, килешенә һәм аны килешенү өчен Хокук идарәсенә җибәрә яисә килешү проектындагы кимчелекләр буенча күрсәтмәләр әзерли һәм, кимчелекләрне бетерү өчен, әлеге күрсәтмәне ҖММИ бүлеге белгеченә җибәрә

Килешенгән һәм Хокук идарәсенә җибәрелгән килешү проекты

ҖММИ бүлеге белгече килешү проектындагы кимчелекләрне төзәтә һәм архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсенә җибәрә

Хокук идарәсе килешү проектын карап тикшерә, килешенә Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрә яисә килешү проектындагы кимчелекләр буенча күрсәтмәләр әзерли һәм әлеге кимчелекләрне бетерү өчен ҖММИ бүлеге белгеченә җибәрә

Килешенгән һәм имзалау өчен Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрелгән килешү проекты

ҖММИ бүлеге белгече Хокук идарәсе күрсәткән килешү проектындагы кимчелекләрне төзәтә һәм Хокук идарәсенә җибәрә

Башкарма комитет Җитәкчесе килешү проектын имзалый һәм теркәү өчен ҖММИ белгеченә җибәрә

Имзаланган һәм ҖММИ бүлеге белгеченә җибәрелгән килешү проекты

ҖММИ бүлеге белгече килешүне гариза бирүчегә бирә

Гариза бирүчегә бирелгән килешү

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе

Г.К. Әхмәтова

Башкарма комитетның
2018 елның 29 ноябрендәге
7120 нче карарына
4 нче кушымта

Муниципаль милектәге җир участогын
сатулар үткәрмичә сату буенча
муниципаль хезмәт күрсәтүнең
административ регламентына
кушымта (белешмә)

Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен җаваплы
һәм аның үтәлешен контрольдә тотуны гамәлгә ашыручы вазыйфаи затларның
реквизитлары

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Башкарма комитет Җитәкчесе | 30-55-42 | kancel.chelny@tatar.ru |
| Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы | 30-55-54 | uzioIP@yandex.ru |
| Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы урынбасары | 30-55-54 | uzioIP@yandex.ru |
| Башкарма комитет җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсенең җир ресурслары белән идарә итү бүлеге башлыгы | 30-59-72 | uzioIP@yandex.ru |
| Башкарма комитет җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсенең җир ресурслары белән идарә итү бүлеге белгече | 30-55-54 | uzioIP@yandex.ru |

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтова